СОВЕТ
ЛЕВАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЛЕВАШЕВО
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

08.04.2026

№ 18

с.Левашево

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Левашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 100 номерлы «Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указына туры китереп,

**Левашево авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Левашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының түбәндәге карарларының үз көчен югалткан дип танырга:

- «Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 20.11.2014ел, №100 карары;

- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге Советының 20.11.2014ел,№100 карарына үзгәрешләр кертү турында» 17.11. 2023 ел, № 56 карары;

- «Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Советның 20.11.2014ел, №100 карарына үзгәрешләр кертү турында» 24 .06.2024ел, № 71 карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе** **С.А.Демидова**